**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2023 елның 21 ноябре №176

**Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының «Апас шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 2023 елның 20 гыйнварындагы 131 номерлы карары белән расланган Апас шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә :

1) 4.13 пунктында икенче җөмләне алып ташларга;

2) 4.19 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4.21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.21. Муниципаль хезмәткәргә сыйныф чины бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә сыйныф чины бирү турында тәкъдим кертелгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча, органга яки җирле үзидарәнең сыйныф чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына класс чины бирү турында Карар кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге башлыгына йөкләргә.

Апас шәһәр тибындагы бистәсе
муниципаль берәмлеге Башлыгы
Апас шәһәр җирлеге
Советы рәисе А.Г.Җиһаншин